| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

3 июнь 2019 ел № 36/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында " 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен расларга (кушымта 1).

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2017 елның 31 гыйнварындагы 14/6 номерлы «Өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) формалаштыру,

алып бару (шул исәптән ел саен өстәп тору) һәм мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен раслау турында» карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының Икътисад, инвестицияләр, авыл хуҗалыгы, җир мәсьәләләре, эшмәкәрлек һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә бастырып чыгарырга.

5. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Советының
03.06.2019 ел № 36/3
карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) иректе муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибе "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне алу үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген (алга таба – Исемлек) формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару кагыйдәләрен җайга сала.

1.3. Исемлек әлеге Тәртип нигезендә төзелә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы тарафыннан раслана.

1.4. Күрсәтелгән Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәт аны озак сроклы нигездә (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта

эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга хуҗалык итү һәм (яки) файдалануга бирү максатларында кулланыла, шулай ук "Дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендаланучы күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүсез нигездә бирелергә мөмкин.

## 2. Исемлекне формалаштыру тәртибе

2.1. Исемлеккә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) азат ителгән, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлекка ярдәм күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар карамагында булган мөлкәт кертелә.

Муниципаль унитар предприятиегә хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында, муниципаль учреждениеләргә оператив идарә итү хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәт әлеге предприятие яки учреждение тәкъдиме буенча һәм тиешле мөлкәт белән алыш-бирешләр килештерергә вәкаләтле җирле үзидарә органы ризалыгы белән "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында билгеләнгән тәртиптә аны кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга хуҗалык итү һәм (яки) файдалануга бирү максатларында исемлеккә кертелергә мөмкин.

2.2. Исемлеккә кертелгән мөлкәт аны озак вакытка (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләре һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә бирү максатларында файдаланылырга мөмкин, шулай ук "Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда түләүсез нигездә бирелергә мөмкин.

2.3. Исемлекне формалаштыру Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының исемлекне раслау яки аны үзгәртү турындагы карары проектын әзерләүдән яки агымдагы елның 1 ноябренә кадәр тиешле

мөлкәтне Исемлеккә кертү яисә аннан төшереп калдыру юлы белән өстәмә кертүдән гыйбарәт.

2.4. Исемлекне алып бару тиешле муниципаль милек турындагы мәгълүматларны аңа кертү, Исемлекне үзгәртү һәм тулыландыру, шулай ук аны электрон һәм кәгазь рәвештә саклаудан гыйбарәт.

2.5. Исемлеккә кертелергә тиеш түгел:

- җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен файдаланыла торган күчемсез милек, шул исәптән балалар бакчалары һәм мәктәпләр биналары;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фараз планына (программасына) кертелгән мөлкәт;

- Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 1-10, 13-15, 18 һәм 19 пунктчаларында каралган җир кишәрлекләре, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш.

2.6. Муниципаль милек объектлары түбәндәге очракларда Исемлектән төшереп калдырылырга мөмкин:

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә хуҗа булу һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен объект кирәк түгел;

- бүлмәләрне муниципаль яки дәүләт ихтыяҗлары өчен куллану зарурлыгы;

- закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә объект Россия Федерациясе дәүләт милкенә яки Татарстан Республикасы дәүләт милкенә тапшырылган очракта;

- объект "Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүле читләштерелгән очракта.

Муниципаль милек объектларын Исемлектән төшереп калдыру кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерә торган оешмалар белән төзелгән мөлкәт белән идарә итү һәм (яки) файдалану килешүләрен туктату өчен нигез булып тормый.

2.7. "Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 8 һәм 9 пунктларында күрсәтелгән очраклар нигезендә мондый мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә

түләүле читләштерүдән тыш, Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне сату тыела. Күрсәтелгән мөлкәткә карата шулай ук алардан файдалану хокукларын башкаларга тапшыру, алардан файдалану хокукын залогка тапшыру һәм мондый мөлкәттән файдалану хокукын теләсә кайсы хуҗалык эшчәнлегенең башка субъектларының устав капиталына кертү, мондый мөлкәтне арендалау килешүләре буенча хокукларны һәм бурычларын өченче затларга тапшыру (яңадан рәсмиләштерү), мондый мөлкәтне субарендага тапшыру, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмалар тарафыннан субарендага тапшырудан тыш, һәм субарендага "Көндәшлекне яклау турында" 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктында каралган мөлкәт бирелү очрагыннан башка, тыела.

## 3. Исемлекне алып бару тәртибе

3.1. Исемлек Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан расланган белешмәләр тапшыру формасы һәм составы нигезендә исәпкә алу объектының тасвирламасын, аның адресын һәм техник характеристикаларын күрсәтүне үз эченә ала.

3.2. Исемлекне формалаштыру һәм алып бару, шулай ук аңа кергән объектларны исәпкә алу Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.3. Исемлекне алып бару кәгазь һәм электрон чыганакта башкарыла.

Муниципаль милекнең мәгълүматлар базасын алып бару аңа исәпкә алу объектларын һәм алар турындагы мәгълүматларны кертүне, исәпкә алу объектлары турындагы мәгълүматларны яңартуны һәм расланган Исемлеккә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очракта аларны мәгълүматлар базасыннан төшереп калдыруны аңлата.

3.4. Реестрдагы исәп объектлары турындагы мәгълүмат кызыксынган затларга Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелә.

3.5. Расланган исемлек турында, шулай ук аңа кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү корпорациясенә тапшырыла. Күрсәтелгән мәгълүматларның составы, аларны тәкъдим итү вакыты, тәртибе һәм формасы эшмәкәрлек эшчәнлеген, шул исәптән урта һәм кече бизнесны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

## 4. Исемлекне рәсми бастырып чыгару тәртибе

4.1. Исемлек, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль

районының рәсми сайтында һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати ярдәм рәсми сайтларында урнаштырылырга, шулай ук "Туган як"газетасында мәҗбүри бастырылырга тиеш.

4.2. Исемлекне раслау, аны үзгәртү һәм аңа өстәмәләр турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карарлары рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.